Муса Җәлил! Муса Җәлил!
Халкыбыз каһарманы
Үлемсез аның исеме,
Мәңгелек аның даны!

1906нчы ел, 15нче февраль – герой шагыйрь - Муса Җәлил туган көн. Шул уңайдан “Себер тракты тарихы һәм Муса Җәлил музее”нда шагыйрьне искә алу чарасы узды. “Кызыл ромашка штабы”на кабул ителгән укучыларыбыз Муса Җәлилнең шигырьләрен сөйләделәр. Музей җитәкчесе Фирая ханым шагыйрьнең “Моабит дәфтәрләре” турында кызыклы мәгълүматлар җиткерде. Укучыларыбыз Муса Җәлил кебек батыр, көчле булырга ант иттеләр. Чара “Салют сиңа, Муса Җәлил” җыры белән тәмамланды.







